

Әйе, дорестән дә кеше хезмәте зур әһәмияткә ия. Һәрвакыт тынгысыз хезмәттә булган, конен тонгә ялгап эшләгән кеше генә тормышта vз урынын таба ала. Хезмәте барнын гына хормәте бар.
Мордовия Республикасынын «2 нче балалар поликлиникасы» дәvләт бюджет учреждениесе кvп профильле амбулатор дәвалау учреждениесе булып тора. Поликлиника Саранскнын Ленин һәм Октябрь районнарында яшәvче балаларга хезмәт кvрсәтә, ана 15 000 гә якын бала беркетелгән. Анда балаларга югары технологик дәрәҗәдә квалификацияле һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме кvрсәтелә. Шул учреждениядә 32 ел тырышып хезмәт итvчеләрнен берсе Гульнара Фәрит кызы Долотказина.  Ул торле дәрәҗәдә эшләгән: хужалык эше буенча учреждение житәкчесе урынбасары да, хужалык бvлеге житәкчесе дә - ничек кенә әйтелсә дә кул астында эшләгән дистәдән артык хезмәткәрдән ин беренче чиратта бар эштә тәртип булуын таләп итv жинел тvгел. Нинди генә һонәр иясе булмасын, vз хезмәтен яратып, яхшы итеп башкарган, vзенен эше белән бик кvпләрне бәхетле иткән затлар гына хормәткә лаек. “Хезмәте барнын - хормәте бар” - дип юкка гына әйтмәгән бит халык. Авырлыклардан курыкмыйча эш яраткан, кулыннан эш килгән Гульнара Фәрит кызын пациент балалар, аларнын әти-әниләре, поликлиника хезмәткәрләре, житәкчеләре- бар да хормәт итә. Анын һәрвакыт vз урыны, vз юлы бар. Эшеннән тәм, ләззәт тапкан кеше vзен бәхетле тоя. Ул һәр иртә соенеп эшенә бара, кvнелен биреп эшли. Хезмәте белән башкаларга, иленә файда китерvенә куана. Нинди генә авырлыклар булса да, куркып калмый, тырышлыгы белән куйган максатларына ирешә, яна vрләр яулый, дәрәҗәләргә ирешә. Шуна анын тырыш хезмәте югары бәяләнә дә: октябрь ае азагында тантаналы рәвештә ана Россия Федерациясе Минздравынын Почетная грамотасы тапшырылды. Бvген ул лаеклы Хезмәт ветераны.
Гульнара Фәрит кызы Наиль Шәмил улы белән ике бала тәрбияләп vстерәләр, ике оныклары - Алиса белән Марк аларны шатландырып тора. Гульнаранын оендә дә тәртип. Милли ризыклары остәленннән тошми. Бигрәк тә пәрәмәч, бәлешләре тәмле. Киләчәктә

тагы зур унышлар котсен, сау-сәламәт бул.